| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 сентябрь г.Казань № 916

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына 3 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 ноябрь, 1048 нче; 2020 ел, 28 гыйнвар, 33 нче; 2020 ел, 26 февраль, 147 нче; 2020 ел, 27 июль, 626 нчы; 2020 ел, 9 ноябрь, 1002 нче; 2020 ел, 1 декабрь, 1078 нче; 2021 ел, 3 февраль, 52 нче; 2021 ел, 23 апрель, 279 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт

программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасына 3 нче кушымтага, 43 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Сатып алына торган (шул исәптән өлешле төзелеш объекты булып торган) торак урын яки торак йорт төзелеше Татарстан Республикасы территориясендә булырга яки гамәлгә ашырылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин